РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ГЛАВА САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

27.01.2022

№ 7-п

“Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Нырты авыл җирлеге” муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты турында фикер алышу буенча ачык тыңлаулар билгеләү хакында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 5.1., 24 һәм 28 статьялары һәм “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясындагы 4 өлеше, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” Татарстан Республикасы Законының 15 статьясындагы 5 өлеше, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Уставының 19 статьясы, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Советының 2006 елның 21 ноябрендәге 94 номерлы карары белән расланган Саба муниципаль районында ачык тыңлаулар турындагы Нигезләмә нигезендә, авыл җирлекләренең җирле үзидарә органнары вәкаләтләре муниципаль районнарның җирле әһәмияттәге мәсьәләләре булып торуын һәм авыл җирлекләре территорияләрендә муниципаль районның җирле үзидарә органнары тарафыннан хәл ителүен исәпкә алып, ачык тыңлаулар аша халыкның фикер алышуда катнашу хокукларын үтәү максатыннан

КАРАР БИРӘМ:

1. 2022 елның 28 февраленә “Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Нырты авыл җирлеге” муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләре проекты буенча ачык тыңлаулар үткәрүне билгеләргә.

2. Ачык тыңлауларның оештыручысы итеп Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы авыл җирлекләрендә җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проектын әзерләү буенча Комиссияне билгеләргә;

3. “Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Нырты авыл җирлеге” муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча ачык тыңлауларны түбәндәге адреслар һәм вакыт буенча үткәрергә:

– Татарстан Республикасы, Саба муниципаль районы, Олы Нырты авылы, М.Җәлил урамы, 13а йорт, Олы Нырты авыл мәдәният йорты бинасы, 08.00 сәгатьтә;

– Татарстан Республикасы, Саба муниципаль районы, Завод Нырты авылы, Завод урамы, 17в йорты, Завод Нырты урта гомум белем бирү мәктәбе бинасы, 09.00 сәгатьтә;

– Татарстан Республикасы, Саба муниципаль районы, Чәбия Чүрчи авылы, Ә.Кәримуллин урамы, 27а йорты, Чәбия Чүрчи авыл клубы бинасы, 10.00 сәгатьтә;

– Татарстан Республикасы, Саба муниципаль районы, Урта Нырты авылы, Х.Такташ урамы, 22б йорты, Урта Нырты авыл клубы бинасы, 11.00 сәгатьтә;

**4.** Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проектына тәкъдимнәр һәм искәрмәләр, шулай ук чыгыш ясау хокукы белән ачык тыңлауларда катнашу өчен гаризалар Саба муниципаль районы, Байлар Сабасы ш.т.б., Г. Закиров урамы, 52 йорт, 105 кабинет адресы буенча тапшырылырга мөмкин (эш көннәрендә 8:00 сәгатьтән 16.30 сәгатькә кадәр). Чыгыш ясау хокукы белән ачык тыңлауларда катнашу өчен гаризалар бирү вакыты – 2022 елның 28 феврале. Тәкъдимнәр һәм искәрмәләр шулай ук ачык тыңлауларда катнашучылар җыелышын үткәрү вакытында да язма рәвештә яки телдән дә бирелергә мөмкин.

**5.** Ачык тыңлауларны Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Советының 2006 елның 21 ноябрендәге 94 номерлы карары белән расланган Саба муниципаль районында ачык тыңлаулар турындагы Нигезләмәдә билгеләнгән тәртипкә нигезләнеп үткәрергә.

**6.** Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы авыл җирлекләрендә җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проектын әзерләү буенча Комиссиягә:

– 2022 елның 28 февраленә кадәр әлеге карарны проект белән бергә "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Саба муниципаль районы рәсми сайтының (http://saby.tatarstan.ru) "Ачык тыңлаулар" бүлегендә, шулай ук Татарстан Республикасының Хокукый мәгълүматлар турындагы http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында бастырып чыгарырга;

– Ачык тыңлаулар үткәрелә башлау турында Саба муниципаль районының http://saby.tatarstan.ru рәсми сайтында, авыл җирлеге бинасы янында урнашкан авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, халык күпләп җыела торган урыннарда һәм җирлек территориясендә урнашкан башка урыннарда, шулай ук Саба муниципаль районы Башкарма комитеты бинасында, шулай ук ачык тыңлауларда катнашучыларның күрсәтелгән мәгълүматка үтемлелеген тәэмин итә торган башка ысуллар белән халыкка хәбәр итәргә. Түбәндәгеләрне урнаштырырга:

1) ачык тыңлауларда каралырга тиешле проект һәм аңа карата мәгълүмати материаллар урнаштырылган рәсми сайт турында мәгълүмат, җыелыш яки ачык тыңлауларда катнашучыларның җыелышлары үткәрелү датасы, вакыты һәм урыны турында мәгълүмат.

2) ачык тыңлауларда каралырга тиешле проект турында мәгълүмат һәм мондый проектка карата мәгълүмати материаллар исемлеге;

3) ачык тыңлауларда каралырга тиешле проект буенча ачык тыңлаулар уздыру тәртибе һәм вакыты турында мәгълүмат;

4) ачык тыңлауларда каралырга тиеш булган проект экспозициянең яисә экспозицияләренең ачылу урыны, датасы, мондый проект экспозициясен яисә экспозицияләрен үткәрү вакыты, күрсәтелгән экспозицияне яки экспозицияләрне карау мөмкин булган көннәр һәм сәгатьләр турында мәгълүмат;

5) ачык тыңлауларда каралырга тиеш булган катнашучылар тарафыннан проектка кагылышлы тәкъдимнәр һәм искәрмәләр кертү тәртибе, вакыты һәм формасы турында мәгълүмат;

– "Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Нырты авыл җирлеге" муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре

проектын һәм аңа карата мәгълүмати материалларны Интернет челтәрендә – Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының http://saby.tatarstan.ru рәсми сайтында “Ачык тыңлаулар” бүлегендә урнаштырырга;

– 2022 елның 28 гыйнварыннан алып 2022 елның 28 февраленә кадәр ТР, Саба муниципаль районы, Байлар Сабасы ш. т. б., Г. Закиров урамы, 52 йорт адресы буенча урнашкан Саба муниципаль районы Башкарма комитеты биналарында һәм ТР, Саба муниципаль районы, Олы Нырты авылы, Муса Җәлил урамы, 13 А йорты адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йорты бинасында ачык тыңлауларда каралырга тиешле җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты экспозицияләрен ачарга һәм үткәрергә. Экспозициячне эш көннәрендә 8:00 сәгатьтән 16:00 сәгатькә кадәр карарга мөмкин. Экспозиция эше барышында экспозициягә килүчеләргә консультация бирү, ачык тыңлауларда каралырга тиешле проект турында мәгълүмати материаллар тарату, проект экспозициясенә килүчеләрне исәпкә алу кенәгәсендә (журналда) язылу юлы белән тәкъдимнәр һәм искәрмәләр кабул итү оештырылырга тиеш;

– ачык тыңлауларга әзерлекне, ачык тыңлауларда мәҗбүри каралырга тиешле гражданнар һәм вазыйфаи затларның тәкъдимнәрен һәм искәрмәләрен кабул итүне һәм исәпкә алуны тәэмин итәргә;

– билгеләнгән вакыт нигезендә ачык тыңлауларда катнашучыларның җыелышларын үткәрүне тәэмин итәргә;

– ачык тыңлаулар беркетмәсен һәм ачык тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмәне әзерләүне һәм рәсмиләштерүне тәэмин итәргә;

– ачык тыңлаулар нәтиҗәләре турындагы бәяләмәне Интернет челтәрендә - Татарстан Республикасының Хокукый мәгълүматлар турындагы http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында һәм Саба муниципаль районының http://saby.tatarstan.ru рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

7. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә дип билгеләргә.

8. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы авыл җирлекләрендә җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проектын әзерләү буенча Комиссия рәисенә йөкләргә.

Саба муниципаль
районы Башлыгы                                   Р.Н. Минниханов